Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № LVIII-8**

Балык Бистәсе штп. 2025 елның 7 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2021 елның 31 августындагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» XI-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2021 елның 31 августындагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» XI-3 номерлы карарына (05.03.2022 ел №XX-6; 25.05.2023 ел №XXXVIII-6 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.22 пунктында «контрольдә тотылучы затлар белән хезмәттәшлек итмичә» сүзләреннән соң «(мәҗбүри профилактик визит кысаларында мәгълүматларны җыюдан, эшкәртүдән, анализлаудан һәм исәпкә алудан гайре).» сүзләрен өстәргә;

1.2. 2.27.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документлар буенча тикшерү уздыру срогы ун эш көненнән артмаска тиеш. Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан контрольдә тотылучы затка документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны таләптә күрсәтелгән документларны контроль (күзәтчелек) органына тапшыру вакытына кадәр тапшыру таләпләре җибәрелгән вакытка, шулай ук контрольдә тотыла торган затка тәкъдим ителгән документлардагы хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау турында контроль (күзәтчелек) органы мәгълүматы җибәрелгән мизгелдән алып йә әлеге документлардагы белешмәләрнең туры килмәве турында, дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда алынган документлардагы һәм (яисә) алынган документлардагы белешмәләрнең һәм (яисә) дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләрнең булуы хакында мәгълүматлар җибәрелгәннән соң һәм таләпләр күрсәтелгән язма

аңлатмаларны контроль (күзәтчелек) органына тапшырганчы документлар тикшерү үткәрү срогын исәпләп чыгару вакытына кадәр туктатып торыла»;

1.3. 2.27.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Планнан тыш документар тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 маддәсендәге 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә уздырылган очрактан гайре, прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин;

1.4. 2.29.3 пунктын көчен югалткан дип танырга.

1.5. 2.38.1 пунктындагы «һәм (яисә) кулланып» сүзләрен «(урынга чыгып тикшерү уздырудан гайре) һәм (яки) фотога төшереп яисә» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.48.2.1 пунктында «ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә» сүзләреннән соң «мәҗбүри таләпләр» сүзләрен өстәргә, ә «һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар салу) китерүне булдырмау чараларын үткәрү турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.7. 3.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Профилактик визит:

3.6.1. Профилактик визит контрольдә тотылучы затның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча инспектор тарафыннан профилактик әңгәмә рәвешендә яки видео-конференц-элемтә яисә «Инспектор»мобиль кушымтасы ярдәмендә үткәрелә.

3.6.2. Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы затка үз эшчәнлегенә яки аңа караган контроль объектларына куела торган мәҗбүри таләпләр турында, аларның хәвефлелек критерийларына туры килүе, хәвефлелек категориясен киметүнең киңәш ителә торган ысуллары, контроль объектына карата аны хәвефлелекнең тиешле категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган чараларның төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында хәбәр ителә, ә инспектор контроль объекты белән таныша, контроль объектларын хәвефлелек категориясенә кертү өчен кирәкле мәгълүматларны җыя һәм контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен бәяли.

3.6.3. Профилактик визит контроль (күзәтчелек) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яисә контрольдә тотылучы зат инициативасы буенча үткәрелә.

3.6.4. Профилактик визит үткәрү йомгаклары буенча контроль объектына «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»31.07.2020 елгы №248-ФЗ Федераль законның 48 маддәсендәге 6 һәм 7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен гавами бәя бирелергә мөмкин.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов